# КАРАР

## Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге составына керүче Олы Арташ торак пунктында халык җыены нәтиҗәләре турында

27.10.2022 №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының «Арташ авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге Советының 2021 елның 17нче декабрендәге 29 “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда (торак пункт территориясе өлешендә) гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында»карарына таянып 2022 елның 27 октябрендә узган гражданнар җыенында “2023 нче елда Саба муниципаль районының Арташ авыл җирлеге Олы Арташ торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 800(сигез йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә һәм аны түбәндәге максатларда файдаланырга ризамы:

1) Саба муниципаль районының Олы Арташ торак пунктында җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау (грунт эшләү, ком нигезе салу, чүп-чардан нигез салу, юл читләрен урнаштыру, суүткәргеч торбалар урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү)

2) Саба муниципаль районының Олы Арташ торак пунктында күму урыннарны төзекләндерү (металл баганалар кую, профильләрне монтажлау, калиткалар урнаштыру, металл өслекләрне буяу, килешү буенча эшләр өчен түләү)

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә буенча:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 205 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 108 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучыларның _108_е тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның _0_е тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Саба муниципаль районы составына керүче Арташ авыл җирлегенең Олы Арташ торак пунктында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә, дип танырга.

2. 2023 нче елда Саба муниципаль районының Арташ авыл җирлеге Олы Арташ торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 800 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм аны түбәндәге максатларда файдаланырга ризамы:

1) Саба муниципаль районының Олы Арташ торак пунктында җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау (грунт эшләү, ком нигезе салу, чүп-чардан нигез салу, юл читләрен урнаштыру, суүткәргеч торбалар урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү) дигән сорауны кабул ителгән дип танырга.

2) Саба муниципаль районының Олы Арташ торак пунктында күму урыннарны төзекләндерү (металл баганалар кую, профильләрне монтажлау,

калиткалар урнаштыру, металл өслекләрне буяу, килешү буенча эшләр өчен түләү) дигән сорауны кабул ителгән дип танырга

3. Үз көчен югалткан дип танырга:

“Татарстан Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге составына керүче Олы Арташ торак пунктында халык җыены нәтиҗәләре турында” Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге составына керүче Олы Арташ т.п. халык җыенының 2022 елныҗ 08 сентябрендә кабул ителгән №1 карары.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлегенең рәсми сайтында: https://saby.tatar.ru/artash адресы буенча бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге башлыгына әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Җыенда рәислек итүче,
Арташ авыл җирлеге башлыгы А.Р. Әгъләмҗанов